ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 16 һәм 28 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяның 1 өлешендә:
а) 1 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;
б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“3) шәхсән яисә ышанычлы затлар аркылы эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, федераль законнарда башкасы каралмаган булса яисә федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә аңа хуҗалык итүче субъект белән идарә итүдә катнашу йөкләнмәгән булса, мондый оешма белән идарә итүдә (торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек, дача куллланучылар кооперативлары, күчемсез милек хуҗалары ширкәтләре һәм билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һөнәр берлекләре моңа керми) катнашырга;”;

2) 28 статьяның 10 өлешендәге 1 пунктында “яшәү урынын,” сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2015 елның 2 июле
№ 53-ТРЗ